ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.08.2022 Казан ш. № 118

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларга (гидларга), гид-тәрҗемәчеләргә аттестация үткәрү буенча аттестация комиссиясе турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы федераль законның $4^4$ статьясы, РФ Хөкүмәтенең «Экскурсоводларны (гидларны), гид-тәрҗемәчеләрне аттестацияләү турында нигезләмә раслау хакында» 2022 елның 7 маендагы 833 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 елның 12 апрелендәге 234 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.1 пунктындагы унбишенче абзацы нигезендә боерык бирәм:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларга (гидларга), гид-тәрҗемәчеләргә аттестация үткәрү буенча аттестация комиссиясе турында кушымтада бирелгән нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларның (гидларның), гид-тәрҗемәчеләрнең таныклыгын тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасы формасын (2 нче кушымта);

экскурсоводның (гидның) яки гид-тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасы тасвирламасын (3 нче кушымта).

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Г.М.Сафинга йөкләргә.

3. Әлеге боерык 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә һәм 2028 елның 31 августына кадәр гамәлдә була.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2022 елның 02.08.2022 № 118 боерыгына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларга (гидларга), гид-тәрҗемәчеләргә аттестация үткәрү буенча аттестация комиссиясе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларга (гидларга), гид-тәрҗемәчеләргә аттестация үткәрү буенча аттестация комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Экскурсоводларны (гидларны), гид-тәрҗемәчеләрне аттестацияләү турында нигезләмә раслау хакында» 2022 елның 7 маендагы 833 номерлы карары (алга таба – 2022 елның 7 маендагы 833 номерлы карар) нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларга (гидларга), гид-тәрҗемәчеләргә аттестация үткәрү буенча аттестация комиссиясенең (алга таба – Комиссия) эш кагыйдәләрен һәм аны формалаштыру тәртибен ачыклый, Комиссия рәисенең һәм әгъзаларының хокукларын һәм бурычларын билгели.

1.2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы экскурсоводларны (гидларны), гид-тәрҗемәчеләрне аттестацияләү (алга таба – аттестация), әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүләре белән башкасы каралмаган булса, аларның экскурсоводларга (гидларга), гид-тәрҗемәчеләргә (алга таба – дәгъва кылучыларга) таләпләргә туры килүен раслау өчен, Россия Федерациясе гражданнарына карата Комиссия тарафыннан үткәрелә.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы федераль законга, 2022 елның 7 маендагы 833 номерлы карарга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 елның 12 апрелендәге 324 номерлы карарына таянып эш итә.

1.4. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе законнары һәм 2022 елның 7 маендагы 833 номерлы карарда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

1.5. Комиссия Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) боерыгы белән төзелгән һәм, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүләре белән башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе гражданнарына карата аттестация үткәрә торган даими эшләүче орган булып тора.

1.6. Комиссия түбәндәге максатларда оештырыла:

дәгъва кылучылардан квалификация имтиханнарын кабул итү;

аттестация турында яки аттестациядән баш тарту турында карар кабул итү;

квалификация имтиханы өчен сораулар формалаштыру һәм аларны Дәүләт комитетына раслау өчен җибәрү.

1.7. Комиссия Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы, аттестациясе булмаган экскурсоводлар (гидлар), гид-тәрҗемәчеләр тарафыннан экскурсия хезмәте күрсәтү сыйфаты өчен җавап бирми.

1.8. Дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында нигезләмәне һәм аның составы турындагы белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) үзенең рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) урнаштыра һәм актуаль хәлдә тота.

## II. Комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе

2.1. Комиссия әгъзалары составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

Дәүләт комитеты вәкилләре;

туроператорлар, турагентлар, экскурсоводлар (гидлар) һәм (яки) гид-тәрҗемәчеләрнең профессиональ бергәлеген тәкъдим итә торган оешмаларның, экскурсоводлар (гидлар) һәм (яки) гид-тәрҗемәчеләр әзерләүне гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмалары, туристлык эшчәнлеген алып баручы оешмалар, музейлар һәм башка күрсәтү объектлары, мәдәният, тарих, туган якны өйрәнү, сәнгать өлкәсендә фәнни һәм коммерцияле булмаган оешмалар, үзәкләштерелгән дини оешмалар һәм (яки) аларның структурасына керүче дини оешмалар вәкилләре.

2.3. Комиссия 10 кешедән тора һәм Комиссия рәисен, Комиссия рәисе урынбасарын, Комиссия әгъзаларын, Комиссия сәркатибен үз эченә ала.

2.4. Комиссиянең вәкаләтләре:

квалификация имтиханнары үткәрү срокларын билгеләү;

квалификация имтиханнарын кабул итү;

комиссия утырышы беркетмәләрен рәсмиләштерү һәм имзалау;

квалификация имтиханы өчен сораулар формалаштыру һәм аларны раслау өчен Дәүләт комитетына җибәрү.

2.5. Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия сәркатибе Комиссия әгъзалары арасыннан Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

2.6. Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия әгъзалары һәм сәркатибе функцияләре әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

2.7. Комиссия утырышлар рәвешендә эшчәнлек алып бара. Комиссия утырышын уздыру өчен кворум аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысын тәшкил итә.

2.8. Комиссия утырышларны кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр уздыра. Кирәк булган очракта Комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

2.9. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышында турыдан-туры форматта һәм (яки) видеоконференция аша катнаша алалар.

2.10. Комиссия эше белән Комиссия рәисе җитәкчелек итә.

2.11. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда (авыру, ял, командировка һәм башка мөһим сәбәпләр) аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары, ә Комиссия рәисе урынбасары вакытлыча булмаганда, Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия әгъзасы башкара.

2.12. Комиссия рәисе:

Комиссия эшчәнлеген оештыра, шул исәптән Комиссиянең чираттагы һәм чираттан тыш утырышларын чакырта, Комиссия утырышларын алып бара, Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

Комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра;

аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсен (алга таба – Беркетмә) һәм Комиссия эшчәнлегенә бәйле башка документларны имзалый;

Комиссия утырышларында рәислек итә.

2.13. Комиссия сәркатибе:

Комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра;

Комиссия утырышларын үткәрү урыны, вакыты һәм шартларын тәэмин итү турында мәсьәләләрне хәл итә, шулай ук утырышларны үткәрү турында Комиссия әгъзаларына хәбәр итә;

Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышларында фикер алышу өчен бирелә торган материаллар белән таныштыруны тәэмин итә;

Комиссия эшен алып бара;

Беркетмә алып бара, утырышларны видеофиксацияләүне тәэмин итә;

Беркетмәне «Интернет» челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру өчен җаваплы затка тапшыра һәм дәгъва кылучыларга хәбәрләр җибәрә;

Беркетмә күчермәләрен һәм Комиссиянең башка документларын комиссия әгъзаларына һәм вәкилләре утырышларда катнашкан оешмаларга җибәрә;

Комиссия рәисенең башка йөкләмәләрен Комиссия эшчәнлеге кысаларында башкара.

2.14. Комиссия әгъзалары:

Комиссия утырышында катнашалар, карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда һәм карарлар эшләүдә катнашалар;

комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаса, алдан ук (Комиссия утырышы уздырылган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча) бу хакта Комиссия сәркатибенә хәбәр итәләр;

Комиссия эшчәнлегенә кагылышлы документларда билгеләнгән тәртиптә танышалар;

Беркетмә һәм Комиссия эшчәнлегенә бәйле башка документларны имзалыйлар.

2.15. Комиссия әгъзасы җитди сәбәпләр (авыру, ял, командировка һәм башка мөһим сәбәпләр) буенча Комиссия утырышында катнаша алмаса, Комиссия әгъзасы, Комиссия рәисе белән килештереп, экскурсия эшчәнлеге өлкәсендә һөнәри белемнәре булган ышанычлы затны җибәрергә хокуклы.

2.16. Комиссия әгъзалары мәнфәгатьләр каршылыгын, Комиссия әгъзасының шәхси (турыдан-туры яки читләтеп) кызыксынучанлыгы яисә Комиссия әгъзасына йогынтысы (басымы) аның тарафыннан вәкаләтләрне тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган һәм бу вакытта Комиссия әгъзасының шәхси

кызыксынучанлыгы белән Россия Федерациясе гражданнарының яисә Комиссия әгъзасы финанс яисә башка йөкләмәләр белән бәйле булган оешмаларының законлы мәнфәгатьләре арасында әлеге законлы мәнфәгатьләргә зыян салырга сәләтле булган каршылык килеп чыга яки килеп чыгарга мөмкин булган очракларны булдырмас өчен чаралар күрә.

Шул ук вакытта Комиссия әгъзасы тарафыннан үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәүгә тәэсир итә яисә йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынучанлык дигәндә Комиссия әгъзасы, аның гаилә әгъзалары яисә якын туганнары, шулай ук Комиссия әгъзасы финанс яисә башка төр йөкләмәләр белән бәйле булган Россия Федерациясе гражданнары өчен акчалата яки натураль формада керемнәр, турыдан-туры матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге турында сүз бара.

Мәнфәгатьләр каршылыгы килеп туган очракта, Комиссия әгъзасы Комиссия утырышы башланганчы бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта тиешле Комиссия әгъзасы аның белән мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгарга мөмкин булган дәгъва кылучыны аттестацияләү комиссиясе эшендә катнашмый.

2.17. Аттестация комиссиясе әгъзасы булган дәгъва кылучыны аттестацияләү вакытында аның әлеге комиссиядә әгъзалыгы туктатыла.

2.18. Комиссия әгъзалары Дәүләт комитеты тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелә торган апелляция комиссиясе әгъзалары була алмый.

2.19. Россия Федерациясенең ике һәм аннан да күбрәк субъектлары территорияләре буенча уза торган милли туристлык маршрутларында һәм (яки) туристлык маршрутларында хезмәт күрсәтүне күздә тотучы экскурсоводны (гидны), гид-тәрҗемәчене аттестацияләү өчен Комиссия аттестация үткәрүгә, шул исәптән аттестация турында гаризада күрсәтелгән Россия Федерациясенең һәр субъекты комиссиясенең кимендә бер әгъзасын, видеоконференцэлемтә аша катнаширга җәлеп итә.

Комиссия әгъзалары, әлеге пунктның беренче абзацында каралган очракларда, Россия Федерациясе субъектларыннан экскурсоводны (гидны), гид-тәрҗемәчене аттестацияләү турында карар кабул итүдә катнашалар.

2.20. Дәгъва кылучыларның белемнәрен һәм осталыкларын төрле яклап бәяләү, шул исәптән чит телне (чит телләрне) белүләрен бәяләү өчен Комиссия тиешле өлкәдән экспертларны җәлеп итәргә хокуклы.

2.21. Чукракларның һәм начар ишетүчеләрнең белемнәрен һәм осталыкларын бәяләү өчен Комиссия ишарә телен белүче экспертларны һәм (яки) тәрҗемәчеләрне җәлеп итә.

2.22. Комиссия әгъзасы булган вазыйфаи зат вазыйфаларын башкаручы зат Комиссия утырышында киңәш бирү рәвешендәге тавыш хокукы белән катнаша.

2.23. Комиссия утырышларында катнашучы затлар законда саклана торган серне, конфиденциаль мәгълүматны, квалификация имтиханнарында катнашучыларның шәхси мәгълүматларын таратмаска тиеш.

2.24. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар Дәүләт комитетына (420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Максим Горький ур., 19 йорт) турыдан-туры тапшырыла яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша яисә, тапшыру турында белдереп, почта аша яки гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, Дәүләт

комитетының электрон почтасына tourism.rt@tatar.ru «Интернет» челтәре аша яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрелә.

2.25. Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән билгеләнгән Дәүләт комитетының җаваплы хезмәткәре гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларның тулылыгын алар кергән көннән башлап өч эш көне эчендә карый.

Аларны карау нәтиҗәләре буенча барлык документларны Комитет рәисенә тапшыра. Комитет рәисе (яисә аны алмаштыручы зат) дәгъва кылучыны квалификация имтиханын узуга кертү яки кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

2.26. Квалификация имтиханы аттестация комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Аттестация комиссиясе квалификация имтиханнарын үткәрү срокларын билгели. Квалификация имтиханнарын үткәрү вакытлары турында Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы «Интернет» челтәрендәге үз сайтында квалификация имтиханнары башланган көнгә кадәр 30 календарь көннән дә ким булмаган чорда мәгълүмат урнаштыра.

2.27. Дәгъва кылучыны аттестацияләү турындагы карар Комиссия утырышында катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары саны тигез булганда, Комиссия утырышында рәислек итүче затның тавышы хәлиткеч булып тора.

2.28. Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итүне Дәүләт комитеты башкара.

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2022 елның
_______________ № _____
боерыгына 2 нче кушымта

(Рәвеше)

## Экскурсоводның (гидның) яки тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасы

### Экскурсоводның (гидның) яки тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасының АЛГЫ ЯГЫ

| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ<br><br>Элемтә өчен телефон: (842) 222-90-30 | | REPUBLIC OF TATARSTAN<br><br>STATE COMMITTEE ON TOURISM OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN<br><br>Contact number: (842) 222-90-30 |
|---|---|---|

ТӨСЛЕ
ФОТО

Фамилия — Surname

Исем — Name

Ата исеме — Middle name

ЭКСКУРСОВОД (ГИД)/ГИД-ТӘРҖЕМӘЧЕ
TOUR GUIDE/GUIDE-TRANSLATOR

Федераль реестрда теркәү номеры
Registration number in the federal register

Бирү датасы
Date of issue

Гамәлдә булу вакы
Validity period

QR-КОД

Аттестациянең сериясе, теркәү номеры
Series, certificate registration number

Аттестатның гамәлдә булу
Certificate validity period

Бирелде: Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан
Issued: State Committee on Tourism of the Republic of Tatarstan

Дата/Date

Visit Tatarstan

Экскурсоводның (гидның) яки тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасының
ИКЕНЧЕ ЯГЫ

| *Туристлык объекты-ның исеме* | *ел* | *ел* | *ел* | *ел* | *ел* |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлеге
(843) 222-90-30

Visit Tatarstan

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2022 елның ________________ № _____ боерыгына 3 нче кушымта

Экскурсоводның (гидның) яки тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасының тасвирламасы

1. Экскурсоводның (гидның) яки гид-тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасы (алга таба – тәңгәллек карточкасы) пластиктан эшләнә. Тәңгәллек карточкасының алгы ягында урнаштырыла:

1.1. Үзәк өлешеннән өске ягында – Татарстан Республикасы гербы, гербтан сул якта – язу: «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ», гербтан уң якта инглиз телендә кабатлана.

Язулар астында түбәнрәк Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты), инглиз телендә кабатлап, элемтә телефоны күрсәтелә.

1.2. Экскурсоводның (гидның) һәм (яисә) гид-тәрҗемәченең тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасы тасвирламасының (алга таба – Карточка тасвирламасы) 1.1 пунктында күрсәтелгән язу астында:

сулда – тәңгәллек карточкасын алучының төсле фотосы;

фотодан уңда – яз: «Фамилия, исем, атасының исеме», инглиз телендә кабатлана.

1.3. Карточка тасвирламасының 1.2 пунктында күрсәтелгән язу астында урта өлеше буенча махсуслашу күрсәтелә: «ЭКСКУРСОВОД (ГИД)» яки «ГИД-ТӘРҖЕМӘЧЕ», инглиз телендә кабатлана.

«ЭКСКУРСОВОД (ГИД)» язуы зәңгәр (зәңгәрсу төстәге) тәңгәллек карточкаларында башкарыла.

«ГИД-ТӘРҖЕМӘЧЕ» язуы яшел (ачык яшел) төстәге тәңгәллек карточкаларында башкарыла.

1.4. Астарак Карточка тасвирламасының 1.3 пунктында күрсәтелгән язулар, фото астында:

сулда – язу: «Федераль реестрда теркәү номеры», инглиз телендә кабатлана.

Федераль реестрдагы теркәү номеры – экскурсоводларның (гидларның) һәм гид-тәрҗемәчеләрнең бердәм федераль реестрына кертелгән реестр язуының уникаль номеры;

уң якта – QR-код, ул кодлаштырылган рәвештә экскурсоводларның (гидларның) һәм гид-тәрҗемәчеләрнең бердәм федераль реестрының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге битенең адресын анда урнаштырылган, экскурсоводлар (гидлар) һәм гид-тәрҗемәчеләр турындагы белешмәләрдән торган язулар белән бергә үз эченә алырга тиеш.

1.5. 1.4 пунктта күрсәтелгән язу астында урнаштырыла:

сулда – язу: «Бирү датасы», инглиз телендә кабатлана;

уңда – язу: «Гамәлдә булу вакыты», инглиз телендә кабатлана.

1.6.1.4 пунктта күрсәтелгән язу астында урнаштырыла:

язу: «Аттестатның сериясе, теркәү номеры», инглиз телендә кабатлана;

астарак – язу: «Аттестатның гамәлдә булу вакыты», инглиз телендә кабатлана;

тагын да астарак – «Бирелде: Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан», инглиз телендә кабатлана.

1.7. 1.6 пунктта күрсәтелгән язу астында кызыл төстә «Visit Tatarstan» логотибы һәм язуы урнаштырыла.

2. Тәңгәллек карточкасының икенче ягында урнаштырыла:

2.1. Өске якта урта өлеше буенча «Экскурсоводны (гидны) яки гид-тәрҗемәчене аттестацияләү», инглиз телендә кабатлана.

2.2. 2.1 пунктта күрсәтелгән язу астында 5х5 таблица урнаштырыла. Беренче багана атамасы «Туристлык объекты исеме», аннан соң «ел».

2.2 пунктта күрсәтелгән таблица астында «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлеге (843) 222-90-30» дигән язу урнаштырыла.

2.3. 2.2 пунктта күрсәтелгән язу астында кызыл төстә «Visit Tatarstan» логотибы һәм язуы урнаштырыла.

2.4. Тәңгәлләштерә торган күкрәк карточкасының үлчәме:

киңлеге – кимендә 95 мм;

озынлыгы – кимендә 140 мм.